**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**АТНИНСКИЙ**
**РАЙОННЫЙ СОВЕТ**

422750, село Большая Атня, улица Советская, дом 38

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘТНӘ**
**РАЙОН СОВЕТЫ**

422750, Олы Әтнә авылы, Совет урамы., 38нче йорт

Тел.: 8(84369)21004, факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

РЕШЕНИЕ
“24” май 2024 ел

КАРАР
№ 231

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, “Россия Федерациясе Су кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” 2023 елның 25 декабрендәге 657-ФЗ номерлы, “Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында” 2024 елның 15 маендагы 99-ФЗ номерлы Федераль законнарга ярашлы, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законына ярашлы, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Уставын Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарына туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Әтнә район Советы **карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Уставына Әтнә район Советының 28.11.2011 № 37 карары белән расланган (06.03.2012 № 68, 07.09.2012 № 87, 26.11.2012 № 101, 08.10.2013 № 118, 31.07.2014 № 156, 01.04.2015 № 178, 31.03.2016 № 32, 04.08.2017 № 76, 16.04.2018 № 107, 20.05.2019 № 156, 14.04.2020 № 201, 30.10.2020 № 14, 26.01.2021 № 34, 04.10.2021 № 68, 27.01.2023 № 163 үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. 6 нчы статьяның 1 нче пунктының 34 нче пунктчасын “, шулай ук су объектларын рекреацион максатларда куллану кагыйдәләре” сүзләре белән тулыландырырга.

1.2. 64.1 статьясының 2 пунктын түбәндәге эчтәлектәге 5нче пунктча белән тулыландырырга:

“5) аның чит ил агенты статусын алуы.”

2. Әлеге карарны законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәве өчен җибәрергә.

3. Әлеге карарны Әтнә муниципаль районының www.atnya.tatarstan.ru рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының www.pravo.tatarstan.ru рәсми порталында һәм «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең

(функцияләрнең) Бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында бастырып чыгарырга;

4. Әлеге карар «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясының 8 өлешенә ярашлы рәвештә үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Әтнә муниципаль районы башлыгы –
Әтнә район Советы рәисе Г.Г. Хәкимов